
Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!


ISSN 0136-7110

Чаян



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ОКТЯБРЬ * 2023 * КАЗАН

10



Валентин ДУБИНИН

Алмаз ХӘМЗИН

ОКТЯБРЬ ХАТИРӘЛӘРЕ

“Октябрьдә туганнарның
Ленин була бабасы”, – дип,
Каяндыр, кемнәрдәндер
Ишеткән сүзләрне кабатлап
Йөри идек балачакта
Мактанып, горурланып.

Менә җитте тагын шул ай…
Оныттык – без кемнеке?
Хәзер бабайлар күп күбен…
Без – әти-әнинеке генә.

Зур бабабыз юк нигәдер,
Бөтен балаларныкы?..
Атабыз Ысталин да юк,
Шуңамы без басынкы?..

Оешмабыз да бар иде –
Галстук тагып йөрдек.
Хәтта октябрятлар булып
Детсадта уйный идек.

Октябрь бәйрәмнәрендә,
Тыгыз колонналарда
Транспарантлар күтәреп,
Дан җырладык Ватанга.

Тантаналарда гынамы
Булды безнең казаныш?!
Күмәклектә, бердәмлектә
Яуланылды зур уңыш!

Явыз дошман илгә бәреп
Кергән чакта аяусыз,
Бөтенебез күтәрелде –
Булалмадык намуссыз!

Гел ашкындык биеклеккә,
Галәм йөрешләрендә,
Космос белән җенләнепләр
Бетә идек төшләрдә.

Менә шул Октябрьнең
Күңелгә салган моңы
Һаман җилкендерә безне –
Онытмыйк, дуслар, моны!

Игорь КИЙКО



ШОМБАЙ болай диде…



Хөрмәтле Чаян! Иске машинамны яңага алыштырырга булдым. Акча җыйнап автосалонга бардым һәм хыялларымның тормышка ашмаячагын аңладым. Яңа машиналарның бәяләре шаккаттырды, ә тотылганнарныкы куркытты. Ватан автопромының иң гади эшләнмәсе миллионнан ким түгел, ә кытай дусларныкы якын килерлек тә түгел иде. Җыйган акчаларым белән салоннан чыгып китәсе генә калды…

К. ВӘЛИЕВ

КАЗАН

– Автомобиль затлы әйбердән хәрәкәт чарасына әверелгәнче дистәләгән еллар узды. Кызганыч, кире юлны без берничә атна эчендә үттек, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

Фәнзаман БАТТАЛ

УФТАНМАГЫЗ!

– Үтте-китте елгыр яшьлек,
Атландырып таякка.
Шул таякта бар таяныч,
Атласам да кай якка.

Әй ул яшьлек!.. Бер елмайсам,
Кызлар алды кочакка!
Иллә яши белер идем,
Кайтып булса шул чакка!

Һи-и, бу картлык... Аяк-кулда
Калмады гел егәрлек...
Тартып карыйм уңга-сулга –
Өзеп булмый тегәрҗеп...

Теге хаста, бу хаста –
Билне бөгәләр аска.
Яшьлек үткәч, ни хәл итмәк:
Өмет калмады башка.

... И бабайлар, уфтанмагыз,
Картлыкны тетә-тетә.
Теткән-сүккәнгә карамый,
Картлык та үтеп китә!





Матур фасад артында

Мул гына акчалар түләп, башларын ипотека камытына тыгып, көтелгән яңа фатир алучылар гаиләләре өчен ышанычлы, тыныч һәм рәхәт тормыш башлануын көтәләр. Үз йортыңа үзең хуҗа, шатланып яшә генә. Ләкин күчемсез милек һәрчак оҗмахтагыдай гомер итү бирми икән, бигрәк тә хәзерге яңа йортларда. Заманча торак сатып алу еш кына бетмәс-төкәнмәс проблемаларны хәл итүгә әверелә.

Җиренә җиткереп, сыйфатлы материаллардан, кирәкле инфраструктура белән төзелгән күп катлы йортларны бармак белән санап чыгарга була. Ә менә берөзлексез төзелеп торган күпсанлы "кеше оялары"на дәгъва җитәрлек. Мәсәлән, Казандагы «ArtCity» торак комплексында яшәүчеләр күршеләрендә нәрсә эшләнгәнен һәрвакыт белеп торалар. Әмма сез аларны бергәләшеп гомуми йорт чатында аралашып торалар дип уйлый күрмәгез. Йортларда тавыш изоляциясе шундый ки, һәр төчкерек күршеләргә ишетелеп тора. Бер-берсеннән бернинди сер юк – моның өчен төзүчеләргә рәхмәт укыйсы гына кала.

Сабир Әхтәмов урамында урнашкан "Мой ритм" торак комплексының да үзенчәлекләре җитәрлек. Ул үтеп баручыларны заманча дизайн һәм бизәлеше белән, ә фатир хуҗаларын кыек стеналары белән җәлеп итә. Тик болар Чистай урамындагы бизнес-классլы "Столичный" торак комплексы белән чагыштырганда чүп кенә. Монда матур фасад артында коелып төшкән штукатурка, тишек торбалар, фатирлардагы салкын яшеренгән.

Ә менә "Экопарк Дубрава" торак комплексында яшәүчеләр үзләрен алданган итеп тоялар. Фатирларны сатып алганда аларга сихри урман манзарасы, тынлык һәм саф һава вәгъдә иткән булганнар. Болар булган, ләкин озак түгел: хәзер ул манзараны төзелеш материаллары склады һәм биотуалетлар каплап тора. Урман һавасы урынына башка исләр иснәргә туры килә. Ә калган буш урында киләчәктә тагын ике күп катлы йорт төзү планлаштырылган. Вәгъдә ителгән табигать белән берләшеп яшәү өметләрен юкка чыгарачак бу. Өстәп шуны да әйтергә була: Дәрвишләр бистәсендәге "Экопарк Дубрава" торак комплексын, гомумән, котельный белән янәшә куйганнар, төтен турыдан-туры тәрәзәләргә бәреп керә.

Болар яңа торакияләрен борчыган проблемаларның кечкенә өлеше генә. Моңа әле кипмәгән стена һәм балконнар, йортларны басып алган күгәрек, бүлмәләр эчендә уйнап торган җил, инфраструктура булмауны да өстәргә була… Бу исемлекне чиксез дәвам итәргә мөмкин. Мондый торакның ныклыгы да бик шикле. 30 елга дип төзелгән атаклы "хрущёвка"лар инде ярты гасырдан артык торалар, аларны сүтәргә җыенмыйлар да. Ә хәзерге күп катлы йортларның, матур кыяфәтләренә карамасан, гомере озын булырга охшамаган. Белгән кешеләр фикеренчә, бу күз ачып йомганчы торгызылган корылмаларга 15–20 елдан соң капиталь ремонт кирәк булачак, ә кайберләрен сүтеп ташларга туры киләчәк. Кызганыч, төзелеш хуҗаларын беренче чиратта тиз генә килә торган керем кызыксындыра. Ә аннан соң инде ни булса шул була!

Бүгенге төзүчеләрнең элеккегеләрдән бердәнбер уздырып җибәргән ягы – ул да булса "шедевр"ларына яңгыравыклы исемнәр бирә белү: "Якты кала", "Кояшлы ялан", "Язгы бакча", "Хыял" һәм хәтта "Бәхет"… Комплексларның сырлы-бормалы исемнәре аларның җитешсезлекләре санынннан кимрәк гаҗәпләндерми. "Көймәне ничек атасаң, ул шулай йөзәр" дигән әйтем дә, нишләптер, эшләми.

Людмила САФИУЛЛИНА



Виталий ПОДВИЦКИЙ

Валентин ДУБИНИН



Михаил ЛАРИЧЕВ





• • •

Көтү алдыннан зур мөгезле кыңгырау таккан тәкә бара. Сарыклар аның аларны кая алып барганын белә. Ә тәкәнең бары тик алдан гына барасы килә – тузансыз саф һава, һәм жаның теләгән тәмле үлән!

• • •

Фатир хуҗабикәсе яшәргә кергән студент кыздан сорый:

– Нишләп абыең килми башлады?

– Ул, кабахәт, яңа сеңел тапкан.

• • •

– Телевидение ярдәмендә күбрәк укый башладым.

– Шаяртасыңмы әллә?

– Юк, чын-чынлап. Анда җыен чүп-чарны күрсәтәләр – карыйсы да килми.

• • •

Мәктәптәге математика курсыннан тормышта бары тик бер генә фразаның кирәге чыкты: ул да булса – “Что и требовалось доказать”.

• • •

ЗАГСка барганда, нигәдер, фаралары белән берәү дә күз кысмады.

• • •

Кибеттә үзеңә үзең хезмәт күрсәтү кассасы урнаштырдылар. Хәзер аның янында һәрвакыт өч кеше басып тора: ялгыш бәя кертелү сәбәпле – ачкыч белән өлкән кассир. Шуны төзәтү өчен – техник, чөнки касса бик еш ватылып тора һәм махсус каравылчы. Монысы инде берәү дә әйбер чәлдермәсен өчен.

• • •

– Ни өчен бездә түрәләр урлый?

– Чөнки судья – үлчәүле сукыр хатын. Ә анда үткен күзле балта тоткан ир булырга тиеш.

• • •

– Кадерлем, кичке ашка нәрсә?

– Грузин ризыклары.

– О! Хачапури? Чахохбили? Цинандали?

– Ашанәрсәбиргәнне!

• • •

Әби белән бабай ялгышларын кабатламаска булдылар һәм колобок урынына кубик пешерделәр.



ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Һәр кеше башкалар өчен – кагыйдәләр, ә үзе өчен мөмкинлекләр ясый.

Штраф – үзеңне начар тоткан өчен салым. Салым – яхшы эшләр өчен штраф.

Кайбер кешеләр болыт кебек. Алар киткәч, дөнья яктыра.

Мин үз-үзем белән сөйләшәм. Кайчагында акыллы кеше киңәше кирәк бит.

Табигать безгә дүшәмбене ял көннәрендә кылган гамәлләребез өчен җәза итеп биргән.

Төнлә ашау зыянлы булгач, суыткыч эчендә нигә ут яна соң?

Киләчәк никадәр ерак булса, шулкадәр матуррак күренә.

Табигать җирдәге бөтен тереклекне яраткан, ә калганы Кытайда эшләнгән.

Сергей ЖУКОВ

Гадәти хәл

Күптән беләм инде, әгәр хатыннар ирләре белән ызгышканда җиңә алмаса, нигәдер, тормыш-көнкүреш темасына күчәләр. Менә әле генә хатыным белән гаиләбездә туган каршылыклы хәлне чишә алмый интектек: автомобильне кышкы тәгәрмәчләргә күчерергәме, әллә аңа чәшке тун алыргамы. Теләкләр аерылды, дәлилләр бетте, һәм бәхәс вакытлыча тынды.

– Ә син әле соңгы тапкыр башыңны кайчан юдың? – ди бу миңа көтмәгәндә, сынаулы караш ташлап.

– Әйбәтләп, график буенча, бер ай элек, – дидем, хәрбиләрчә рапорт биреп.

– Әйе, әнә, күренеп тора, – дигән сүз ташлады хатын, елан кебек ыслап. – Башыңда берни селкенми шуңадыр, – ди.

– Шулай, чынлап, йоклар алдыннан гына төрле уйлар килә, акыллы фикерләр борчый башлый.

– Кара син аны, – диде хатыны артистларча кулын җәеп. – Аның әле башында уйлар да бар икән!

– Әллә минем башым бигуди өчен генә дип белдеңме? – дип котыртып куйдым моны. – Акыллы фикерләр миндә аркылып ята...

– Менә-менә, хезмәт хакың турында шулай әйтсәң идем! – Моны инде ул гел әйтеп тора.

– Фәндә исбатланганча, акчасы күп кеше – дөньяда иң бәхетсез кеше, – дим мин, сүзен әйтеп бетергәнен көтмичә.

– Шундый кеше белән аз булса да яшәп алсаң иде, – ди хатын, ә үзе үткен карашы белән мине күзәтә.

– Беләсеңме, – дим мин моңа үзәгенә үтеп керерлек итеп. – Әгәр машинаның двигателе йөрәк булса, тәгәрмәчләр – аяк, ә шиналарның нинди хәлдә икәнлеге – ул безнең куркынычсызлыгыбыз...

Шул вакыт ул аякларыма карады да:

– Карале, сиңа күптән яңа башмаклар алырга кирәк бит, – ди.

– Мин инде аларга күнектем. Шундый җайлы, рәхәт алар аякка, ә яңасын алырга барырга кирәк, сайларга, сатып акча сарыф итәргә, аякка әле ул кайчан җайлаша. Акчабыз да аз, чак-чак кына тәгәрмәчкә җитә – шиналар очсыз түгел...

– Шулайга бөгәрсең әле дип уйлаган идем аны... – ди бу.

Шунда телефоны шалтырады.


– Әлү, Сания, сине ишетүемә бик шат. Әлбәттә, сөйләшә алам, әлбәттә, вакытым бар...

Мин җиңел сулап куйдым, талашуга күчәчәк бәхәс шулай итеп өч-дүрт сәгатькә алгарак күчте.

Виктор ФЁДОРОВ









Абау!

ХЕЗМӘТ ТЕРАПИЯСЕ

Татарстанда Эчке эшләр министрлыгының медицина бүлеге башлыгын эш көче файдаланудан гаеплиләр. Тикшерү органнары 5561 нче хәрби часть солдатларының артык еш авырып, министрлык госпиталендә дәваланып ятулары белән кызыксынган. Әмма тикшерү нәтиҗәсендә сугышчыларның ат кебек таза булганнары ачыкланган. "Авыру" солдатларны частьтан алып китеп, офицерларның шәһәр янындагы йортларын төзүдә кара эшчеләр сыйфатында файдаланганнар икән. Баш табибка ялган процедуралар һәм аларга тотылган акчалар өчен зур срок яный, ә мәҗбүри хезмәт терапиясе оештыруда катнашкан башка шәхесләр белән тикшерү эшләре алып барыла.

ТӨРМӘ БИЗНЕСЫ

2 нче номерлы төзәтү колониясе хезмәткәре акча эшләргә булган. Эш бирүчене озак еллар эзләргә туры килмәгән – хөкем ителгәннәрнең берсе аңа төрмәгә наркотиклар китереп торырга тәкъдим иткән. Кече инспектор җиң сызганып эшкә керешкән. Катлаулы схема буенча, аңа акча күчергәннәр, ә ул иректә, кирәкле матдәләрне табып, тимер рәшәткә артына ташып торган. "Наркобизнес"ның өстенә басканчы, инспектор 150 мең сум һәм рәшәткә артына кереп утырырга өлгергән.

ӨЧ БОРЫНГА

Мөслим районында хастаханә җитәкчелеген хезмәткәрләренең хезмәт хакына кул сузган өчен хөкем итәчәкләр. Өч баш җитәкче – баш бухгалтер, баш табибның икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары һәм баш табиб үзе хезмәткәрләрен "талап" ятканнар. Төрле ясалма сәбәпләр белән алар 25 кешелек персоналның хезмәт хакыннан үзләренә өлеш чыгарганнар. Ак халатлы кешеләр 2,1 миллион сумнан колак какканнар.

ЧҮП ТУРЫНДАГЫ ЗАКОН – ЧҮПЛЕККӘ

Чүпне аерым җыю экспериментында Казан үзенең җиңелүен таныды. Бернichә ел элек республикада көнкүреш калдыкларын бүлү турында закон кабул ителгән иде. Ишегалларында сары металл читлекләрдән ясалган күрсәткечле контейнерлар барлыкка килде. Ләкин чүп монополисты "Торак-коммуналь хуҗалыгы предприятиесе" идарәче компания фикеренчә, халык бу яңалыкны аңламады һәм чүпне елеккечә – кая туры килә, шунда ташлый бирде. Бөтен чүпне бер үк машинада чыгарырга туры килде. Шуңа күрә, халыкны бутамас өчен, күрсәткечләрне алып ташларга, ә сары читлекләрне, җанны тынычландырыр өчен, шул килеш калдырырга булдылар.





Игорь КИЙКО

Әмир ХӘБИБУЛЛИН


ИПИ АЛЫРГА ТАКСИДА

Исегездәме, күптән түгел генә әле такси иҗтимагый транспорт төренә әйләнеп беткән иде. Бернечә йөз сумга көнен дә, төнен дә шәһәрнең теләсә кайсы җиренә барып җитәргә була иде. Дөрес, белгән кешеләр мондый "коммунизм" озакка түгел, бөтен дөньяда такси арзан нәрсә түгел, бездә дә бәяләр үз урынына кайтачак, дип кисәткәннәр иде.

Дәүләтебез бу өлкәдә тәртип урнаштырырга булды һәм 1 сентябрьдән такси өчен яңа кагыйдәләр гамәлгә кертелде. Хәзер һәр теләгән көньяк егете һәм җирле "бомбила" элекке кебек ирекле рәвештә таксист булып йөри алмый. Моның өчен рәсми рөхсәт алырга һәм юридик шәхес, эшмәкәр йә үзмәшгуль булып теркәлергә кирәк. Шулай ук "яшел күзле" такси белән идарә итүдән хөкемгә тартылганнарны һәм ЮХИДИ штрафларын түләмәгәннәрне дә мәхрүм иттеләр. Бу яңалыкка каршы килү кыен: күзенә карау белән: "Праваңны кайда сатып алдың?" дип сорыйсы килгән "таксист"ларны кем генә очратмаган икән.

Элекке ирекле тормыш бетерелү белән бәяләр дә сизелерлек дәрәҗәдә күтәрелде, әлбәттә. Казанлылар сүзенә караганда, ике тапкыр диярлек. Такси йөртүчеләр моны автомобильләргә һәм запчастьларга бәяләр күтәрелү һәм таксистларга таләпләр арту белән аңлата. Өстәвенә, көз белән бәйле – пассажирлар саны арту, уку елы башлану һәм начар һава торышы. Әмма иң мөһиме – яңа кагыйдәләр кертү нәтиҗәсендә кискен рәвештә такси йөртүчеләр саны киму.

Күргәнебезчә, "тәртип урнаштыру", гадәттәгечә, пассажирларның кесәсен саектыруга кайтып кала. Алда аларны нәрсә көтә? Бу сорауга бөтен нәрсәне белеп торучы таксистлар да, күпсанлы экспертлар да җавап бирә алмый. Шунысы гына анык: иске фильмда әйтелгәнчә, безнең кешеләр ипи алырга таксига утырып йөрмиләр һәм йөрмәячәк тә...



Вячеслав ШИЛОВ

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Михаил МИХАЙЛОВ

ЯХШЫ УРЫН САЙЛАУ...

Гомерем буе бер урында утырып берни эшләмичә яшәргә җай эзләдем. Шунда бөтен нәрсә булсын: кабинет, кофе-чәй китереп тора торган секретарь, эштәге автомобиль һәм шуның ише кирәк-яраклар. Хезмәт хакының да әйбәт булуы шарт, бөтен нәрсәне сатып алырлыкка җитсен, әле артып та калсын. Ул урын "алтын урталыкта" торырга тиеш, инде хезмәт баскычында үрләгәннәр бөтенесе эшләсен! Түбәндәгеләр дә! Бу – катгый таләп! Тыныч яшәүнең һәм төп тотрыклылыкның нигезе.

Шундый урынны табу һәм төпләнү – бу әле җитте дигән сүз түгел. Ә менә аны ничек саклап калырга? Сак булу һәм уяулык кирәк! Монда осталык таләп ителә, махсус квалификация!

Астан бернинди үтенеч-киңәш кабул итмәскә һәм өскә үткәрмәскә. Аллам сакласын! Хәтта яхшы киңәш тә үзендә куркыныч яшереп ятадыр, ягъни җылы урыныңнан коры калырга мөмкин! Таулардагы ишелүләр бәләкәй генә ташларның коелуыннан башлануы мәгълүм бит инде...

Әгәр өстәгеләр сорауны аска тапшырырга киңәш итсәләр! Ничек кирәк, шулай җавап бирсеннәр.

Әгәр сорау астан килә икән, ул нәрсәне бюрократик тәгәрмәчкә кертергә кирәк. Анда аларның үтенече әйләнер, әйләнер дә онытылыр һәм югалыр, ә үзегез шул урында калырсыз, тынычлыгыгыз да, тотрыклылыгыз да.

Их, тапсаң иде шундый урынны...

ТОРМЫШ КАНУННАРЫ

Елмаегыз... Иртәгә хәлләр начарланачак.

Бөтен начар нәрсә берьюлы килә.

Әгәр үзеңне яхшы хис итәсең икән, борчылма. Бу – озакка түгел.

Һәр әйбәт башланган әйбер начар тәмамлана.
Ә һәр начар башланган әйбер тагын да начаррак тәмамлана.

Кая барсагыз да, юл – тауга, ә җил каршыга булачак.

Майны ипинең кайсы ягына ягасын алдан белеп булмый.

Төшеп киткән һәрнәрсә бүлмәнең иң ерак һәм кул җитми торган урынына тәгәрәп керә.

Әгәр берни дә барып чыкмый икән, инструкцияне укып карагыз. Ләкин ул барыбер эшләмәячәк.



Николай ВОРОНЦОВ



ЯЛГАН ПОДПОЛКОВНИК

Якутиядә яшәүче бер хатын иренә оригиналь бүләк – югары белемнең ялган дипломын бүләк иткән. Бүләк бик файдалы булып чыккан. Катыргы ярдәмендә Руслан Тюмцевның җирле Эчке эшләр министрлыгында карьерасы тиз үскән. 16 ел эчендә бу кеше подполковник дәрәҗәсенә күтәрелгән һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Якутия буенча мәгълүмати элемтә һәм мәгълүмат саклау үзәге башлыгы булып эшләгән. Хатыны белән ул күптән аерылышкан, ләкин аның бүләге хезмәт итүченең тормышын тагын бер тапкыр кискен үзгәрткән – ул эшеннән азат ителгән һәм аңа җинаять эше кузгатылган.

ДИПЛОМЛЫ КУРЬЕР

Сораштырулар күрсәткәнчә, курьерларның 40% югары яки тулы булмаган югары белемгә ия. Тапшыру хезмәтендә эшләгән һәр өченчесе сертификатлы белгеч инженер-техник квалификациягә ия, 17% финанс яисә икътисадый белемгә ия, ә курьер рюкзаклары белән йөгерүчеләрнең 10% – IT-белгечләр. Аларның күбесе өчен бу – өстәмә эш. Курьерның кереме төп эш урынындагы хезмәт хакыннан шактый зур.

БАКЧАДА


Ставрополь өлкәсендә пенсионер һәм аның ике дусты бакча тормышын җиңеләйтергә булганнар. Моның өчен алар 20 мең сумга ... ике кол сатып алганнар. Полиция бакча җәмгыятенә килгәнче, Үзбәкстаннан килгән хатын белән ир, илдә законсыз булганга, алты ай дәвамында хуҗаларына эшләгәннәр. Яңа барлыкка килгән кол хуҗаларын кешеләрне ирекләреннән законсыз мәхрүм итүдә һәм законсыз миграция оештыруда гаепләгәннәр. Аларга законсыз мигрантларны кем сатканы әле дә ачыклана.

КӨТКӘН УРЫН

Мәскәүдә яшәүче берәү Төзелеш министрлыгына эшкә урнашырга теләгән. 70 яшьлек танышы аңа бу эштә булышырга алынган, хезмәтен 9 миллион сумга бәяләгән. Ләкин эшкә урнаштыру 7 елга сузылган. Йә туры килә торган урын булмаган, йә бушы булмаган. Бу еллар эчендә мошенник танышыннан 3 миллион сумга якын акча алган. Ахыр чиктә эш эзләүче көтүдән арыган һәм акчаны кире кайтаруны таләп иткән, әмма хәйрияче шундук юкка чыккан. Булып чыкмаган Төзелеш министрлыгының уңышсыз хезмәткәре полициягә мөрәҗәгать иткән.



Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Виталий ВЕСНИН

Төштәге хыянәт

Шимбәнең бер иртәсендә шулхәтле рәхәт кәеф белән уянуымны хатынымның сөмсере коелган кыяфәте бозды. Сораштыра торгач, төшендә мин сөяркәсе белән йоклаганмын икән, тегесе башка шәһәрдә яшәсә дә. Кофемны эчеп бетергәнче аңа тугры булуым турындагы антымны кабатладым. Ниһаять ул "эреде", ләкин мин үз эшләрем белән маташканда, кинәт усал итеп:

– Туктале, син минем сердәшемә массаж ясадың, ә миңа?

Шулай итеп, миңа ярты сәгатьләп массаж хезмәте йөкләмәсен үтәргә туры килде. Инде мин үземнең гаебемне тулысынча акладым дип уйлап, үз эшләрем белән шөгыльләнгәндә, хатын кинәт:

– Аңламадым, син аны кинога алып бардыңмы, ә минем аннан кай җирем ким?

Кичен аны романтик мелодрамага чакырырга туры килде. Дөресен генә әйткәндә, без ул кичне бик матур үткәрдек, кино карагач кафеда утырдык һәм сәүдә үзәгеннән чыккан чагында, зәркән кибете күреп, ул кинәт, маңгаена сугып, кычкырып ук җибәрде:

– Алка! Син аңа бриллиантлы алка бүләк иттең!

Кичәбезне бозмас өчен, кибеткә керергә риза булдым, һәм ул өч бриллиантлы алка күреп, болай диде:

– Менә шундый!

– Син бит бриллианты берәү генә дип әйттең?! – дип, ялганын тоткандай, әйтеп куйдым.

– Белеп тор: ул сөяркә генә бит, ә мин – хатының! Шуңа күрә ташлары күбрәк булырга тиеш!

Бәхәсләшеп торуны кирәк түгел дип уйлап, бирештем. Бу вакытта сатучы алкаларны киеп каратырга кереште.

– Менә ул – хыянәтеңә түләү! – дип сөйләнә әле хатын, үч итеп...

– Белегез, – дидем мин тынычлыкны бозып, – хыянәт, чынлыкта, төштә генә иде!

Кем ышансын, менә шундый зәркән кибетендәге һавалы сатучы һәм бриллиантлы алка сатып алырга маташучы клиент, елмаеп, шашып көлә-көлә, төшемә керде, дисәм.



Алмаз ГЫЙМАДИЕВ

ВОЛОНТЁРЛАР

Мулланур абый күптән кузгатылмаган пластинкалар арасыннан үзенә кирәген эзләп тапты да, аны радиола тәлинкәсенә урнаштырып, тирән креслога чумды. Йөрәкләрне җилкетеп, җыр яңгырады:

Взвейтесь кострами, синие ночи...
Мы – пионеры, дети рабочих...

Их! Бар иде бит Мулланурның да пионер вакытлары, тимурчылар булып шау-гөр килеп йөргән чаклар... Хәтерендә: шулай бервакыт аларның отряды авыл читендәге Миңниса әбине шефлыкка алырга барды. Малайлар кар көрәде, кызлар әбинең идәнен юып чыгардылар. Шунда отряд советы председателе Гөлназ Мулланурны дәшеп кертеп, диван астындагы үлгән тычканны тышка чыгарып ташларга кушкан иде. Мулланурмы? Һәй! Башта тычканның койрыгыннан тотып әйләндерә-әйләндерә бөтен кызларны чинатып йөрде әле ул. Аннан соң гына ишектән башын тыгып карап торган Тузикка биреп җибәрде. Әй тиргәгән иде соң Мулланурны Миңниса әби.

Ә бервакыт алар – өч малай – туксан яшьлек Сәйфелмөлек бабайның утынын кистеләр. Мулланур анда ике пычкы, бер балта сындырган иде бугай. Әллә ике балта, бер пычкымы?..

Тимер-томыр җыю нык истә калган. Планны тутыра алмагач, парктагы бер тракторның арткы мостын сүтеп алып төшкәннәр иде...

Их, пионер чакларның кабатланмас хатирәләре диген! Кинәт аның уйларын бүлеп, кыңгырау чыңлады. Ишек төбендә ике малай басып тора иде.

– Без – волонтёрлар! – дип таныштырды малайларның озыны. – Сезгә булышырга килдек!

– Кем, кем? – дип сорады бабай.

– Хәтерлисезме, элек тимуровецлар бар иде, без шундыйраклар. – дип аңлатты малай.

– Юк, юк! – дип каршы төште Мулланур. – Бөтен нәрсәм тәртиптә.

– Шулай да бүлмәгезгә күз салыйк әле, бәлки, батареягыздан су агадыр?

Ул рөхсәтсез-нисез генә түргә узды да су торбаларын электр чыбыкларын тикшерә башлады. Мулланур абый бераз тынычланып:

– Паласларымны кагып бирсәгез ярар иде үзе...

– Тә-әк, бер сәгатьтән палас кагарга кызлар килеп җитәр. Ә безгә – дәлше! – диде малай эшлекле кыяфәттә һәм иптәшен ияртеп чыгып та китте.

Мулланур абый янә креслога чумды. "Ә шулай да яшьләр начар түгел хәзер", – дип уйлап куйды.

Ике малайны исә подъезд төбендә колга буйлы, тәмәке капкан бер егет каршылады?

– Ну?! – диде ул.

– Әллә ни юк. Иске радио, иске төсле телевизор, азрак хрустальләр, китаплар, пластинкалар...

Аның сүзен бүлеп, ачык тәрәзәдән җыр агылды:

Взвейтесь кострами, синие ночи...



Сергей АНДРИАНОВ

Дамир МОРТАЗИН

Африкага барасым килә

Төшке аштан соң йоклап алыйм дип, диванга яттым. Хатыным кибеткә китте, биш яшьлек улым, идәндә утырып, телевизор карый. Барысы да ял итәргә җайланган иде. Күземне йомып өлгермәдем, улым кулымнан тартты.

– Әти, ә нишләп безнең өйдә бегемот юк?

– Кем юк, кем? – дип аптырап калдым.

– Бе-ге-мот, – дигән сүзен кабат өзеп-өзеп кабатлады улым. Йокым качты.

– Бездә бит бегемотлар яшәми, алар Африкада гына.

– Алайса, әйдә, Африкага барыйк!

– Африка бик еракта, анда бару бик кыйбатка төшә. Безнең акчабыз җитмәс...

– Җитә, әти, җитә! Син әбидән сора...

"Тапкансың кемнән сорарга", – дидем мин тёщам турында уйлап.

– Улым, хәтта аның да ул хәтле акчасы юк...

– Африкага барасым килә! – дип шыңшый башлады бала. – Африкага! Бегемот сатып ал...

– Юк, алмыйбыз! – дидем мин кырт кисеп. – Без аны кайда тотарбыз? Фатирыбыз бәләкәй.

– Ванныйда...

– Ә нәрсә ашатабыз?

– Ботка һәм ипи белән...

– Әйттең сүз... – дип ухылдап куйдым мин.

Каршы килгәнемне сизеп, улым кабат үзенекен тукый башлады.

– Африкага барасым килә, Африкага... – Күзе яшькә күмелде.

– Җитәр. Тукта шыңшуыңнан!

– Туктамыйм. Африкага барам...

Шунда миңа уй килде.

– Яхшы, әйдә, җыен, киттек Африкага! – дип әйттем дә, ачынып, диваннан күтәрелдем.

– Ура! Хәзер үкме? – дип шатланды бала.

– Әйе! Ләкин иң элек хастаханәгә барып прививка ясатыйк.

– Уколмы? – дигән пошыну сүзе чыкты аннан.

– Әйе, аны ясатмыйча Африкага кертмиләр. Киттекме?

Улым тынды.

– Әтием, мин болай уйладым: нәрсәгә безгә бегемот? Ул бит күп ашый, күп урын ала... Миңа песи баласы ал.

– Яхшы, уйлармын, ә хәзергә миңа ял итәргә комачаулама...









Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, 1964 ел.



Леонид ЕЛЬКОВИЧ, 1965 ел.

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

БЕЗ – "ЧАЯН"ЛЫ ХАЛЫК!

Быел "Чаян"га 100 яшь тулды. Мин дә шактый еллар бу журналда хезмәт итәм. Монда килүем юкка түгелдер, чөнки үземне хәтерләгәннән бирле мин һаман да шул яраткан журналым белән.

Әле дә исемдә – балачак... Ай саен көтеп алган журналыбыз "Чаян" иде. Хәрефләрен укый белмәсәм дә, рәсемнәрен бик кызыксынып карадым.

Әнием мәктәптә укыган вакытта мәктәп стенгазетасы редакторы булган. Һәм ул газетаның исеме... "Чаян". Шул чакта ук ул шаян шигырьләр, мәкаләләр уйлап чыгарырга яраткан.

Әтием дә бик шук кеше булган. Күрше балалары әтиемнең исемен белмәгәннәр. "Шомбай абый" дип йөрттеләр. Чынлап та, бик шаян кеше иде ул, эшендә дә шаярырга яраткан. Гомере буе шундый булды.

Мәктәп яшеннән үземә дә "Чаян" кушаматы тагылды.

"Чаян" сүзе бик үткен, чаян кебек чага торган – аңа эләксәң, бетәсең...

Берзаман күрше хатыны кердә дә әниләргә сөйли: "Тикшерүчеләр йөргән йортлар буенча, ут урлаучыларны тотканнар. Бездән ерак түгел йорттагы күршеләрне".

"Чаян"га да язып чыктылар шуларны. Иң зур хурлык булгандыр бу вакыйга. Соңыннан ут урлаучылар күренмәде безнең тирәдә.

Тагын бер мисал: "Чаян"ның дәрәҗәсе турында. Суыткычыбыз ватылды. Эссе җәй көннәре. Ремонтка алып киттеләр. Бер атнадан була дип вәгъдә бирделәр. Атна үтте – юк суыткыч. Әтием мастерскойларына китте.

– Әйе, абый, эшлибез, бер атнадан китерәбез, – дигәннәр. Тагын бер атна үтте, тагын суыткыч юк. Бер ай үтеп бара. Әтиемнең түземлеге бетеп, барып әйткән – сезне "Чаян"га гына язып чыгасы калган, дип. Мастер, әтиемне ияртеп, цехларына алып кергән дә кайсы суыткыч сезнеке, дип сораган. Безнең суыткыч, мескен, бер почмакта тузанга батып тора икән. Әтием шуңа күрсәткән. Икенче көнне иртә таңнан төзәтелгән суыткычны китереп бирделәр.


Менә бит, "Чаян" дигән сүз генә дә куркытып тора!

Хәзер журналыбыз өлкән яшьтә булса да, мин аңа бирешмәскә, кыю, гадел язмалары белән алдагы көннәрдә дә югары дәрәҗәле, халкыбызның яраткан журналы булып калуын теләр идем.


Бирешмә, "Чаян"! Тагын күп еллар яшә, кешеләрне сөендереп, көлдереп, тәрәге булып!

АШЫГЫЗ ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Валерий ТАРАСЕНКО



Вячеслав ШИЛОВ



Виталий ПОДВИЦКИЙ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Ике дус очраша:

– Синең машина сатып алуың турында ишеттем?

– Әйе. Элек ничек яшәгәнмендер?! Хәзер барысына да өлгерәм! Кичә бер көн эчендә маен алыштырырга җитештем, яңа тәгәрмәчләр алдым, авторынокка барып крылолар алдым да автосервиска җилдерттем һәм куйдырттым аларны. Аннан соң әле бер кибеттән туңмый торган сыекча да табып, багына салдырттым. Машинам булмаса менә боларны ничек эшләп өлгергән булыр идем?!

• • •

Белдерү:

– Мин – матур хатын-кыз. Эш сөюче, таза-сау ир-ат эзлим. Бераз үзем турында: ике йөз сутыйлы бакчам бар, тракторы булса, бик шат булыр идем.

• • •

– Беләсезме, ир-ат йөрәгенә үтеп керү – аның ашказаны аша...

– Юк белән маташмагыз инде... Әллә сөяркәсе янына ирегез бәлеш ашарга йөри дип уйлыйсызмы?

• • •

– Хәзер карьера баскычы буйлап менәргә бик авыр, дисезме?

– Алай гына да түгел: ул баскыч янына якын килүе дә кыен.

• • •

– Бузова концертына билет кирәкме?

– Бәясе купме соң?

– Бушка бирәм бит!

– Кыйбатрак түгелме...

• • •

Безнең ишегалдында ярлылар өчен “Арзан торак” программасы буенча йорт җиткезделәр. Хәзер «лексусл»ар һәм «инфинити»лар аркасында машина куярга урын юк.

• • •

Әгәр дә сезнең дусларыгыз арасында табиблар булса, игътибарга алыгыз: барлык медицина белгечләре арасында бары тик патологоанатом гына иң якын дус булыр.

• • •

Бер-берсенең контентын урламый торган бердәнбер сайт – һава торышыныкы. Алар барысы да төрле мәгълүмат тараталар.



БЕЛЕМ АЛУ КЫЕНЛЫКЛАРЫ

Хөрмәтле редакция! Заманнар шундыйракка китте бит әле, баланы мәктәпкә озатканда, ирексездән аның өчен борчыла башлыйсың. Авылдагы безнең мәктәп тә шул хәсрәткә батыра. Аның бинасы моннан илле ел элек төзелгән һәм бер мәртәбә дә юньле ремонт ясалмаган – ничек җимерелмичә торганына шаклар катасың. Шушы белем учагы ташландык хәлдә. Нигезе ярылып беткән, штукатуркасы коелган, тишекләреннән җил өрә, тәрәзәләре ябылмый. Ашханәгә һәм физкультура дәресенә 130 бала икенче җиргә йөри.

Без инде үз көчебез белән бинаны төзекләндерергә тырышабыз, ләкин хакимият ярдәменнән башка моны үтәп чыгып булмас шул. Менә инде быел да шушы ремонт кермәгән килеш уку елын башладык. Югыйсә белем алу бала өчен иң мөһим мәсьәлә, ә нинди шартларда һәм нихәтле сыйфатлы рәвештә бирелгәне – монысы бүтән нәрсә...

Яңа Кәшер мәктәбе укучыларының әти-әниләре.

ӘЛМӘТ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

КҮБЕКЛЕ ЯЗМЫШ

Кадерле "Чаян!" Күпләргә мәгълүм: мәхәббәт алиһәсе Афродита диңгез күбегеннән туган. Безнең Шанхай күлендә дә еш кына андый күбекләр күбекләнеп ала. Ләкин никадәр могҗизалы икәнне тикшереп торырга кирәкми. Каян килеп чыга ул, аның тикшерүче органнар да белми. Шикаять язуыбыз була, белгечләр килә, суның составын тикшерә һәм нормага ярый дигәнне билгеләп китәләр. Хәтта гаепләләр дә табылганын әйтәләр, штраф салынганын да исбатлыйлар. Ишетүебез буенча, күлдән ерак булмаган сөт комбинатыннан яки сыра заводыннан нәрсәдер агызалар. Бар халык белә, ләкин сероводородлы ис аңкуы дәвам итә. Шуңа күрә күлне коткару аянычлы, ә безнең сәламәтлек – Алла кулында...

Н. ГАБДРАХМАНОВА

ОТАР бистәсе
КАЗАН


Илдар НӘФИЕВ


Виктор БОГОРАД



Максим СМАГИН

Михаил ЛАРИЧЕВ





2023 елның 1 сентябрендә журналыбызның даими авторы, танылган шагыйрь, күп әдәби конкурслар лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Рашат Миссар улы Низамиев (Рашат Низами) вафат. Гаиләсенең, туганнарының авыр кайгысын уртаклашабыз. Дустыбызның якты истәлеге күңелләрдә мәңге сакланыр.

"Чаян" журналы коллективы.

Үзе биреп киткән, әмма әле басылырга өлгермәгән ике язмасын тәкъдим итәбез.

ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

Рашат Низами:
Җырланмаган җырлар кала бездән,
Ә Җир куйнында
Ятып кала – көл һәм күлгә.
Алмаз Хәмзин:
Җырлаганы җитәр, Рашат дускай,
Сиңа-миңа күкрәк кагып:
– Без яшәдек! – диеп үләргә!
Р. Н.: Картаюның ни икәнен белми –
Күңел унҗидедә, һаман яшь сәнә!
А. Х.: Ә бит гомер чикле, йөрәк әйтә:
– Син теләсәң нишлә, мин – пенсиядә!..
Р. Н.: Заманага ачы сүгенеп,
Төнне, ахры, куркыттым...
А. Х.: Төннең исе дә китмәгәндер –
Карчыгыңны уяттың.
Р. Н.: Бүре бик еш айга карап улый,
Айның ләкин кителгәне юк.
А. Х.: Без дә күккә карап ялварабыз,
Тормышыбыз ләкин, шулай ук...
Р. Н.: Әй син, сеңел! Мөлдерәмә итеп
Салып бирче "ачы" тустаган...
А. Х.: Ни кыланмак буласың, карт тиле, –
Син бу "эштән" күптән туктаган.
Р. Н.: Коммунизм белән саубуллаштык
Киләчәккә юллар ярганда...
А. Х.: Килеп терәлдек чын тупикка –
Капитализм дигән аранга.
Р. Н.: Чынбарлыктагы хәлләрне
Телевизор шомарта...
А. Х.: Хезмәт хакын, пенсияне
Арттырдык дип шаярта.

ҖӨМЛӘЛӘР

- Куян белән төлкенең үбешкәнен күрүче юк әле.
- Парнас тауга менеп җитәм, дип, күпме шагыйрь канатын сындырды.
- Шайтаным да илһам килмәс иде, "Чаян" дустым әгәр булмаса.
- "Жираф нигә озын муенлы" дигән темага диссертация язды кыска муенлы галим.
- Туган телем – диңгез, сүзем диңгездән бер тамчы.
- Акчаң булса гына аптека сине ярдәменнән ташламас.
- Намусын югалтыр өчен, кешегә иң әүвәле намуслы булу шарт.
- Гарип күңелдә төзек уйлар була алмый.
- Кара сакаллы кешедә дә аксакаллар акылы булырга мөмкин.



Алмаз ХӘМЗИН

ТЕЛЕВИЗОР КАРАГАНДА...

Авылларда телевизор карый башлаган чор. Иң беренче булып яңа әйберне бездә бабам Зиннур Хәмзин алып кайта торган иде. Велосипед белән шулай булды. Шаккаттылар инде. Аннан соң беренче телевизор алып кайтучы булдык. Аңа антенна баганасы куюы – үзе бер мәзәк. Багана ничаклы озын, ягъни биеккә куелса, телевизор шулхәтле әйбәтрәк күрсәтә икән. И-и, аны торгызганда кешенең күп җыелуы, төптән чокырга батырып, сәнәк-тырма, терәгечләр белән көчәнә-көчәнә күтәрүләр, ә ул, сыгылып, антенналы башы җирдән дә калыкмый. Кыскартырга мәҗбүрләр. Шулай итә-итә барыбер бастырып куялар. Боргычлап, канал көйләү өчен дә чөй кагалар. Кереп карыйлар өйгә, әһә, күрсәтә – кар яуган кебек, әмма нәрсәдер шәйләргә була. "Хәмзиннәр телевизор алганнар, инде күрсәтә дә икән", дигән хәбәр бөтен авылга тарала. Бөтенесе килеп карап чыгалар. Әти, әни, без – балалар карап утырабыз инде – нәрсәдер бар экранда – күрсәтә бит инде, тагын ни кирәк?!. Килгән-күргән кеше: "Әйбәт икән, безгә дә алырга кирәк булыр", дигән фикергә килеп, кайтып китәләр.

Озак та үтмәде: "Хафизлар алган икән", дигән хәбәр таралды. "Аларныкы әйбәтрәк күрсәтә!" – диләр. Киттек шунда. Халык җыелган, антенналары куелган – биегрәк. Шулай да экраны карлы. Нәрсәдер шәйләнә. Озаграк карап утырсаң, ни дә булса аңлый да башлыйсың. Хафиз абзыйның йөзендә горурлык – телевизор алган бит! Утырды-утырды да әйтә бу:

– Ярый, сез карый торыгыз, мин мунчага киттем, Саҗидә апагыз көтеп торадыр, ди. Хатыны инде.

Ул китеп күп тә үтмәде, телевизор "чыж-ж" итеп гөрләргә тотынды.

Шул вакыт моңа хәтле тыныч кына карап утырган Бәгъдәнур Хиннуры:

– Аһ, анасын сатты, Хафиз, үзләренең мунча кергәнен күрмәсеннәр, дип, кызган ташка су сипте! – диде.

Менә шулай, бездә "Хуҗа Насретдиннәр" бик күп.

ХӨҖҖӘТ БЕЛӘН ЯППАР

Авылыбызның "Чат" дигән урыны бар. Ул – дүрт урамның кибет, мәчет, клуб урнашкан җирендә. Авыл ирләре соңгы хәбәрләр белән танышу, ишетү өчен көн дә шунда җыелалар – гадәткә кергән. Көн әйбәт чагында – тышта, әгәр дә инде яңгыр-фәлән булса, кибеткә керәләр. Кибетче – Хәмит Зиннуры дип йөртәләр иде инде аны, бик тә гадел, абруйлы, үз эшен матур һәм яратып башкара торган абзый. Әйе, менә шунда кереп тулалар. Зиннур абый аларга бер сүз әйтми – тыныч кына ирләрнең авыл һәм дөнья хәлләрен сөйләгәнне тыңлап – эшләп утыра. Билгеле, кибетче хатын-кыз булса, анда җыела алмаслар иде, әхлак ягыннан да, гомумән, төрлечә уйласаң да фикер бер – килешми. Менә шундагы хәл: шаян-шуклык белән булганы. Еш кына ирләр арасында кызык кешеләр дә бар, алар байтак безнең авылда – бу юлы иң каттәләре – Яппар абый (ишле гаилә хуҗасы, ун кыз үстерде микән, төгәл белмим, хәер, үзе дә төгәл белмәгәндер), икенчесе – Хөҗҗәт абый (монысының да шул чама кызлары). Ишек төбенәрәк куелган зур казанны карап йөриләр болар эндәшми-тынмый, кулларын артка куеп. Берәүнең дә боларда исләре юк. Ну йөриләр... Йөрсеннәр, кемнең ни эше бар?.. Шул вакыт Хөҗҗәт абзый телгә килде дә:

– Карале, Хәмитов, бу колхоз өчен кайтарылган казаннарның зуррагы юк идемени, безнең Яппар белән икебезнең гаилә өчен бәләкәйрәк булыр бу. Җитмәсә, берәү генә икән әле, – дип әйтеп куйды.


Ирләр, эчләре катып, тончыга-тончыга көлешергә тотынды.

Яппары:

– Хөҗҗәт, ал син моны сатып, бер пешереп ашагач, миңа биреп торырсың, – дип, көлүчеләр ялкынына кислород сибеп алды.

Миннән кайвакытта сорыйлар:

– Сезнең авылда бөтенегез дә әллә шундыймы – синең төсле мәзәкчәнме? – дип. Менә хәзер аңладыгыз инде.





САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 10 (1935) октябрь 2023
Баш редактор: Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, РФ, РТ, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066 РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 03.10.2023 ел.
Тираж – 2622 Заказ С-2599
Редакциянең адресы: 420066, РФ, РТ, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

СПОРТСМЕНКА, КӨРӘШЧЕ

ЖЫРЧЫ РИММА . . .

ЖЫРЧЫ ЗӨФӘР . . .

“КАРА ДА ГЫНАЙ . . .”

“БЕРСЕ . . . БЕРСЕ ХӨРМӘ”

НОТА

БОРЫНГЫ РИМ ШАГЫЙРЕ

НОТА

“. . . БӘЙЛӘДЕМ”

“. . . ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ”

“ТУГАН . . .”

ЭШ АТЫ

ШАГЫЙРЬ (20-30 нчы ЕЛЛАР)

СЫЕР АВАЗЫ

ХУШ . . .

ЛАТЫШ ШАГЫЙРЕ . . . РАЙНИС

ЖЫРЧЫ УСМАН . . .

“. . . РАЗБОЙНИК”

. . .-КОЛА

. . . БИКТАҺИРОВ

. . . + СӨТ + ЙОМЫРКА = КОЙМАК

. . . КАРАШ

ЖАК-. . . КУСТО

. . . БЕЛӘН ЧҮКЕЧ

“. . . БӨГЕЛЕП ТОРА”

МАҢГАЙГА БӘРӘ ТОРГАН ЭШ КОРАЛЫ

“. . . ХӘЗЕР АРАЛАР”

ЕГЕТ БУЛСА, . . . БУЛСЫН

“. . . БАГА”

“. . . ЕГЕТЛӘР”

. . . УРМАН

“АГЫЙДЕЛДӘ ИКЕ (-1). . .”

4047 $м^2$

ИШАРӘ

“. . . ЧӘЧӘКЛӘР”

БЕР ЯШЬЛЕК КОЛЫН

. . . ИСӘНБӘТ

ЖЫРЧЫ ХӘДИЧӘ . . .

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Нәрсә ул урта яшь?

2. Сәясәтчеләр сайлаучылардан нәрсәсе белән аерыла?

3. Нәрсә ул пеләшлек?

4. Хайван белән кешенең төп аермасы?

5. Талант белән аңгыралык арасындагы аермалык нидә?

6. Гадел кешене сатып алып буламы?

7. Акча өчен йоклаучы иң борынгы һөнәр ияләре?

ҖАВАПЛАР

1. Бу – каршы як җенесне борчый, ләкин бигүк түгел. 2. Сәясәтчеләр үзләренең сайлаучыларын сайлаулар вакытында гына искә төшерә, ә менә сайлаучылар сәясәтчеләрне көн саен исә тоталар. 3. Алан-фикерләр тупланган җир. 4. Хайваннар кешеләрне өйләрендә тотмыйлар. Хәер, мәчеләр бу фикер белән бик килешеп бетмәсләр. 5. Талантта чикләр бар. 6. Сатып алып булмый, ә сатылырга мөмкин. 7. Каравылчы.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 9 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«УЛ ГЫНА АҢЛАР КЕБЕК»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
Ә. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА (Сарман р-ны, Мортыш Тамак ав.),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).


Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**


Виталий ФЕОКТИСТОВ



Үзенең йөз еллык тарихы эчендә «Чаян» күп кенә карикатура, әдәбият һәм журналистика йолдызларын кабызды. **Виталий ФЕОКТИСТОВ** – аларның берсе. Кабатланмас график, үткен темалар авторы, әдәби пародияләр остасы, юмористик шигырьләр һәм хикәяләр авторы – болар барысы да тормыштан иртә киткән талантның кырлары.

Бу көннәрдә Виталий Феоктистовка 70 яшь тулган булыр иде. Бүгенге вернисаж дустыбызның истәлегенә багышланган.







4612750670080